Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Куакбаш авыл җирлегенең
Куакбаш авылы гражданнар җыены
КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә узган «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Куакбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Куакбаш авылында (Совет урамы, Ленин урамы ,М. Җәлил урамы, Х. Такташ урамы, К. Маркс урамы, Маяковский урамы, Тукай урамы, Сәйдәшев урамы, Г. Исхакый урамы, Яшьләр урамы) юлларны кардан чистарту.

2.) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызуны оештыру:

- «Дегет базы» каптажыннан су линиясен төзү һәм ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 529 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 291.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 290 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше, «ТОТКАРЛАНДЫМ» позициясе өчен 1 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш авылы гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге составына керүче Куакбаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Куакбаш авыл җирлеге Куакбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, саны 18 яшькә җиткән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган

акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Куакбаш авылында (Совет урамы, Ленин урамы ,М. Җәлил урамы, Х. Такташ урамы, К. Маркс урамы, Маяковский урамы, Тукай урамы, Сәйдәшев урамы, Г. Исхакый урамы, Яшьләр урамы) юлларны кардан чистарту.

2.) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызуны оештыру:

- «Дегет базы» каптажыннан су линиясен төзү һәм ремонтлау сораулары буенча карарны кабул ителгән дип.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, Куакбаш авылы, Карл Маркс урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан җирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы, 5а буенча урнашкан авыл клубы, Чүте авылында Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан авыл клубы бинасында урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова